РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МИЧАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422055, Республика Татарстан, Сабинский район,
Село Старый Мичан , ул. Школьная , 12
тел. (84362) 42-3-31

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИЧЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422055, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Мичэн авылы., Мэктэп урамы, 12 йорт
тел. (84362) 42-3-31

e-mail: mich.sab@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.09.2018 № 22

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан 2018 нче елның 05 маенда кабул ителгән 12 нче номерлы «Торак төзелеше максатыннан, комплекслы үзләштерү өчен муниципаль милектә булган җирләрдән җир кишәрлеге арендалау килешүләре төзү хокукын сату сәүдәсен оештыру һәм уздыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламенты» карарына үзгәрешләр кертү турында

2018 нче елның 30 августыннан 02-08-02-138-2018 номерлы Татарстан Республикасы Саба районы прокуратурасы протесты нигезендә, һәм 2018 нче елның 3 июлендә 185-ФЗ номерлы “Кече һәм утра эшмәкәрлек субъектларына матди ярдәм итүне киңәйтү максатыннан Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль закон кабул итү сәбәпле, Татарстан Республикасы Саба районы Мичәнавыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Башкарма гомитеты тарафыннан 2018 нче елның 05 маенда кабул ителгән 12 нче номерлы «Торак төзелеше максатыннан, комплекслы үзләштерү өчен муниципаль милектә булган җирләрдән җир кишәрлеге арендалау килешүләре төзү хокукын сату сәүдәсен оештыру һәм уздыру» буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламенты» карары белән расланган «Торак төзелеше максатыннан, комплекслы үзләштерү өчен муниципаль милектә булган җирләрдән җир кишәрлеге арендалау килешүләре төзү хокукын сату сәүдәсен оештыру һәм уздыру» буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.6 пунктын түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац белән тулыландырырга:

“Муниципаль милек исемлегенә кертелгән җирләрдән җир кишәрлеге арендалау килүшеләре төзү хокукы аукционында катнашу өчен, эшмәкәр субъекты булган мөрәҗәгать итүче үзенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына кагылышлы икәнен кәгазь документ рәвешендә яки кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары күрсәтелгән Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла торган бердәм реестр мәгълүматыннан алынган электрон документ рәвешендә тәгъдим итә, яисә үзенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары шартларына туры килүен 24 июль 2007 елның №209-ФЗ “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү” Федераль закон нигезендә хәбәр итә ала”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичәнавыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru./mishan адресы буенча бастырырга.

Мичән авыл
җирлеге башлыгы А.Ә.Гәрәев